КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 6 декабрь г.Казань № 1170

Гражданнар тарафыннан капиталь булмаган корылмалар булып торган гаражлар төзү максаты белән Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләреннән, дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән яки җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен түләү билгеләү тәртибен билгеләү турында

Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{36\text{-}1}$ статьясындагы 2 пункты, «Гражданнарның гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 3 ноябрендәге 85-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Гражданнар тарафыннан капиталь булмаган корылмалар булып торган гаражлар төзү максаты белән Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләреннән, дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән яки җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен түләү билгеләү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына гражданнар тарафыннан капиталь булмаган корылмалар булып торган гаражлар төзү максаты белән муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен файдаланган өчен түләү билгеләү тәртибен раслауны тәкъдим итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 6 декабрь , 1170 нче
карары белән расланды

Гражданнар тарафыннан капиталь булмаган корылмалар булып торган гаражлар төзү максаты белән Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләреннән, дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән яки җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен түләү билгеләү тәртибе

1. Бу Тәртип гражданнар тарафыннан капиталь булмаган корылмалар булып торган гаражлар төзү максаты белән Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләреннән, дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән яки җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен түләү күләмен (алга таба – түләү күләме) билгеләү кагыйдәләрен билгели.

2. Түләү күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$ПР = \frac{P_{ап} \times П_{зу}}{12} \times N,$$

монда:

ПР – түләү күләме, сум;

$P_{ап}$ – граждан тарафыннан капиталь булмаган корылма булып торган гараж төзү максаты белән файдаланыла торган җир кишәрлеге өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир өчен аренда түләве турында» 1995 ел, 9 февраль, 74 нче карары нигезендә исәпләп чыгарылган еллык аренда түләве күләме, кв.метр өчен сум;

$П_{зу}$ – граждан тарафыннан капиталь булмаган корылма булып торган гараж төзү максаты белән файдаланыла торган җир яки җир кишәрлеге мәйданы, кв.метр;

N – календарь ел дәвамында капиталь булмаган корылма булып торган гараж төзү максаты белән җирләрдән яки җир кишәрлегеннән файдалану айлары саны.